**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№3985**
**21.06.2024**

Башкарма комитетның 2023 елның 2 июнендәге 4666 номерлы Карары белән расланган төзелешкә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 25 декабрендәге 627-ФЗ номерлы Федераль законның 1 статьясы, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 51 статьясындагы 7 өлешнең 10 пункты, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы Карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р   Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2023 елның 2 июнендәге 4666 номерлы Карары белән расланган төзелешкә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының 2.6.1 пунктының 11 пунктчасына, аны яңа редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

«11) капиталь төзелеш объектларын төзүне, реконструкцияләүне территорияне комплексլы үстерү турында карар кабул ителгән территория чикләрендә гамәлгә ашыру планлаштырылган очракта, территорияне комплекслы үстерү турында шартнамә күчермәсе, ә территорияне комплекслы үстерү турында карарны тормышка ашыру шартнамә төземичә гамәлгә ашырылган очракта -  территорияне комплекслы үстерү турында карар күчермәсе. Шул ук вакытта, капиталь төзелеш объектларын, Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларының акчаларын җәлеп итеп, комплекслы үстерелергә тиешле территория чикләрендә төзегән, реконструкцияләгән очракта, территорияне комплексы үстерү турында шартнамәне һәм (яки) карарны тапшыру таләп ителми».

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары М.Ә. Фәттаховка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе                                                                                                Ф.Ш. Салахов